Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Ямаш авыл Советы
КАРАРЫ

11 декабря 2020 ел № 9

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлегенең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» 2018 елның 24 августындагы 75 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең айлык акчалата бүләкләү һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» 2020 елның 6 августындагы 658 нче номерлы карары нигезендә

Ямаш авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлегенең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» 2018 елның 24 августындагы 75 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл Советының 2019 елның 05 декабря 79 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. びкарарга 1 нче кушымтадагы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районының Ямашавыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре

| Вазыйфаның исеме | Уникенче төркем хезмәт хакы, сум |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 15753 |
| Авыл башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары | 15292 |

1.2. карарга 2 нче кушымтадагы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларын айлык акчалата бүләкләү күләме”

| Вазыйфаның исеме | Уникенче төркем хезмәт ечен түләү буенча авыл җирлекләрендә айлык акчалата түләү күләме, сум |
|---|---|
| Башлык | 15759 |
| Башлык урынбасары | 11499 |

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле елга җирле бюджетта каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Ямаш авылы, Совет урамы, 109а йорты; Зәй-Чишмә авылы, Верхняя урамы, 186 нчы йорт; Березовка авылы, Үзәк урам, 10 нчы йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, шулай ук «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз кеченә керә һәм 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук менәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Ямаш авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

Ямаш авыл җирлеге
Башлыгы

Е.С. Ларин